ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Экологик хисаплылык тапшыру өлкәсендә таләпләрне камилләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Экологик хисаплылык тапшыру өлкәсендә таләпләрне камилләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгатен кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга җибәрергә.
3. Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару органнарына Татарстан Республикасы Дәүләт Советының әлеге мөрәҗәгатен хуплауны сорап мөрәҗәгать итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 8 июне
№ 2012-VI ДС

**Экологик хисаплылык тапшыру өлкәсендә таләпләрне камилләштерү мәсьәләсе буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В. Мишустинга Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мөрәҗәгате**

Хөрмәтле Михаил Владимирович!

Әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда табигатьтән файдаланучыларның дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына билгеләнгән рәвешләрдә төрле экологик хисаплылык тапшыру бурычы каралган.

Экологик хисаплылык тапшыру сроклары хисаплылык төренә бәйле, бу аерым очракларда хисаплылыкның төрле төрләрендә булган белешмәләрнең бер-берсенә туры килми торган вәзгыятькә китерә.

Мисал итеп, экологик хисаплылыкның түбәндәге төрләрен һәм аны тапшыру срокларын күрсәтергә мөмкин:

1) атмосфера һавасын саклау турында белешмәләр (2-ТП номерлы рәвеш (һава), тапшыру срогы – хисап елыннан соң килә торган елның 22 гыйнварына кадәр («Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан атмосфера һавасын саклауга федераль статистика күзәтүен оештыру өчен статистика инструментлары җыелмасын раслау турында» 2018 елның 8 ноябрендәге 661 номерлы Дәүләт статистика федераль хезмәте боерыгы);

2) җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турында белешмәләр (2-ТП номерлы рәвеш (калдыклар), тапшыру срогы – хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр («Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыкларына федераль статистика күзәтүен оештыру өчен федераль статистика күзәтүе рәвешен, аны тутыру буенча күрсәтмәләрне кертеп, раслау турында» 2020 елның 9 октябрендәге 627 номерлы Дәүләт статистика федераль хезмәте боерыгы);

3) әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү турында декларация, тапшыру срогы – хисап елыннан соң килә торган елның 10 мартына кадәр («Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү турында декларация тапшыру тәртибен һәм аның рәвешен раслау хакында һәм 2017 елның 9 гыйнварындагы 3 номерлы һәм 2019 елның 30 декабрендәге 899 номерлы Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгы боерыкларының үз көчен югалтуын тану турында» 2020 елның 10 декабрендәге 1043 номерлы Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгы боерыгы);

4) җитештерү экология контролен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап, тапшыру срогы – хисап елыннан соң килә торган елның 25 мартына кадәр («Җитештерү экология контролен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап рәвешен раслау хакында» 2018 елның 14 июнендәге 261 номерлы Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгы боерыгы, «Җитештерү экология контроле программасы эчтәлегенә таләпләрне, җитештерү экология контролен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап тапшыру тәртибен һәм срокларын раслау хакында» 2022 елның 18 февралендәге 109 номерлы Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгы боерыгы).

Күрсәтелгән экологик хисаплылык башлангыч исәп, шул исәптән бухгалтерлык исәбе, белешмәләре (мәсәлән, калдыклар белән эш итү буенча актлар) нигезендә формалаша, алар исә бухгалтерлык исәбен әзерләү чорында берничә тапкыр тәгәлләштерелә һәм аларга төзәтмәләр кертелә, аларны иң чик тапшыру срогы – хисап елыннан соң килә торган елның 31 мартына кадәр.

Шулай итеп, еш кына иртәрәк чорда дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына тапшырылган экологик хисаплылыктагы белешмәләр (атмосфера һавасын саклау турында белешмәләр (2-ТП номерлы рәвеш (һава), җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турында белешмәләр (2-ТП номерлы рәвеш (калдыклар) соңрак чорда тапшырылган экологик хисаплылыктагы белешмәләргә (әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү турында декларация, җитештерү экология контролен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисап) туры килми торган вәзгыятькә китерә, чөнки тапшыру сроклары буенча соңрак бирелгән экологик хисаплылык бухгалтерлык исәбен әзерләү өчен кулланыла торган актуальрәк белешмәләр нигезендә формалаша (хисап елыннан соң килә торган елның беренче кварталы). Бу табигатьтән файдаланучыларны Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.5 статьясы (экологик мәгълүматны яшерү яисә бозып күрсәтү) нигезендә административ җаваплылыкка тартуга һәм әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен өстәмә түләүләргә китерә.

Күрсәтелгән вәзгыятьләрне бетерүне табигатьтән файдаланучылар тарафыннан атмосфера һавасын саклау турында белешмәләрне (2-ТП номерлы рәвеш (һава) һәм җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турында белешмәләрне (2-ТП номерлы рәвеш (калдыклар) дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына тапшыру срокларын күчерү мөмкинлеге бирер иде, чөнки мондый очракта, экологик хисаплылыкның күрсәтелгән төрләрен әзерләгәндә, башлангыч исәпнең, шул исәптән бухгалтерлык исәбенең, актуаль белешмәләре кулланылыр иде.

Бәян ителгәннәрне игътибарга алып, хөрмәтле Михаил Владимирович, Сездән федераль башкарма хакимиятнең профильле органнарына табигатьтән файдаланучылар тарафыннан атмосфера һавасын саклау турында белешмәләрне (2-ТП номерлы рәвеш (һава) һәм җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турында белешмәләрне (2-ТП номерлы рәвеш (калдыклар) тапшыру срокларын хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына күчерү мөмкинлеген яисә табигатьтән файдаланучылар тарафыннан әлеге рәвешләр буенча тапшырылган хисаплылыктагы белешмәләрне хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр төгәлләштерү мөмкинлеген булдырырга йөкләмә бирүегезне сорыйбыз.

Шулай ук Сездән федераль башкарма хакимиятнең профильле органнарына бүгенге көндә экологик хисаплылык тапшыруның «Табигатьтән файдаланучының шәхси кабинеты» мәгълүмат ресурсы эшен, түбәндәгеләрне исәпкә алып, камилләштерү мөмкинлеген карарга йөкләмә бирүегезне сорыйбыз:

1) белешмәләр кертелү каралган хисаплылык рәвешләренә табигатьтән файдаланучы тарафыннан тутырылган белешмәләрне автомат рәвештә кертү мөмкинлеге бирә торган унификацияләнгән (башлангыч) рәвеш булдыру. Мәсәлән, хисап чорында барлыкка килгән җитештерү һәм куллану калдыклары турындагы бер үк белешмәләр өч тапкыр түбәндәгеләргә кертелергә тиеш: җитештерү һәм куллану калдыкларын барлыкка китерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру турында белешмәләргә (2-ТП номерлы рәвеш (калдыклар), әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү турында декларациягә, җитештерү экология контролен оештыру һәм аны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре турында хисапка;

2) экологик хисаплылык тапшыру чорында мәгълүмат күп булган мизгелдә «Табигатьтән файдаланучының шәхси кабинеты» системасының техник тотрыклылыгын арттыру, чөнки әлеге мәгълүмат ресурсы эшендә өзеклекләр табигатьтән файдаланучылар тарафыннан күрсәтелгән хисаплылыкны билгеләнгән срокларда тапшыра алмауга китерә.